| ГЛАВА УЛЬЯНКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УЛЬЯНКОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14 ноябрь, 2024 ел Ульянково ав. № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч
муниципаль районы Ульянково
авыл җирлегенең Воскресенский авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 28 ноябренә 09 сәгать 00 минутка Воскресенский авылы, Леваневского урамы, 10 нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлеге Воскресенский торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең Воскресенский авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Ульянково авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга

http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ульянково авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Ульянково авыл җирлеге башлыгы** **Ф.А. Сундурова**